КАРАР
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Советы

1.02. 2019 ел № 112

"“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы Карар проекты турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 маддәссе, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 1 нче кушымта нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы Карар проектын кабул итәргә.

2. "“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм гражданнарның фикер алышуында катнашуы турында”гы Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибен, 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. "“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы Карар проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 2010 елның 29 июнендәге 29 номерлы Карары белән расланган халык тыңлаулары үткәрү тәртибе нигезендә ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт (мәдәният йорты бинасы);

- ТР, Кама Тамагы районы. Тәмте авылы. Октябрь урамы, 65 йорт (АҖ администрациясе бинасы) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының

рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе И. А. Зиновьев

2019 елның 28 февралендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 112 номерлы Карарына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы Карары проекты

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Тәмте авыл
җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 маддәссе, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә”:

1) 8 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

“17) 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы “Кулланучылар хокукларын яклау турында”гы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.”;

2) 32 маддәнең 6 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, Профсоюзда катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; муниципаль берәмлек идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен, гамәлгә куючы (акционер) түләүсез нигездә тәкъдим итү, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган оешмалар яки идарә

итүне гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый акцияләр(устав капиталында катнашу өлешләре) нигезендә; федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;”;

3) 54 маддәгә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы “Кулланучылар хокукларын яклау турында”гы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.”;

4) 90 маддәнең 3 өлешендә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Җирлек халкы саны артуга яки кимүгә бәйле рәвештә, җирлек Советы депутатлары санын арттыручы яки киметүче үзгәрешләр әлеге үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт кабул иткән җирлек Советы вәкаләтләре срогы чыкканнан соң үз көченә керә.”.

2. Кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына җибәрергә.

3. Әлеге Карарны Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе исеменнән түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт (мәдәният йорты бинасы);

- ТР, Кама Тамагы районы. Тәмте авылы. Октябрь урамы, 65 йорт (АҖ администрациясе бинасы) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе И. А. Зиновьев

2019 елның 28 февралендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 112 номерлы Карарына 2нче кушымта

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы Карар проектына
гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу
буенча фикер алышуда катнашу тәртибе

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы Карар проектына тәкъдимнәр Кама Тамагы районының Тәмте авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, ________ факс буенча кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язмача формада:

| | Пункт | Карар проекты тексты | Автор проекты тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8дән 17 сәгатькә кадәр __________ карар игълан ителгән көннән алып мәгълүмати стендларда түбәндәге адреслар буенча кабул ителә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт (мәдәният йорты бинасы);
- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт ( авыл җирлеге администрациясе бинасы).

2. Халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт (АҖ администрациясе бинасы) шәхсән яисә почта аша (“Устав турында фикер алышу” яки “ачык тыңлаулар” конвертында тамгасы белән), шулай ук 8843773176 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында теркәлә һәм карау өчен “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советына тапшырыла.